КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 август г.Казань №932

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1345 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 19 гыйнвар, 23 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибенә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы бюджетын оператив үтәү өчен һәм Министрлыкның боерыгы кабул ителгән вакытка кадәр Татарстан Республикасы бюджетына ачыкланмаган керемнәрне минимальләштерү максатларында Министрлыкка Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе адресына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасына керемнәрне исәпкә алу һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында аларны бүлү тәртибен раслау турында» 2022 елның 29 декабрендәге 198н номерлы боерыгы белән расланган

Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасына керемнәрне исәпкә алу һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында аларны бүлү тәртибенә 7 нче кушымта нигезендә форма буенча бюджет дәрәҗәләре арасында бүлү нормативларын теркәп, бюджет классификациясенә кертелгән үзгәрешләрне «Читтән торып финанс документлары әйләнеше» гамәли программа тәэминатына кертү өчен (баш администраторның Министрлык адресына мөрәҗәгате нигезендә) мөрәҗәгать итәргә рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин